РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА
СТАРОЗЮРИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Школьная ул., д.1А, с. Старые Зюри,
422091
тел. (факс): (84360) 52-6-25,
E-mail: Szur.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ҖӨРИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

Мәктәп ур., 1 нче А йорт, Иске Җөри
авылы,422091
тел. (факс): (84360) 52-6-25,
E-mail: Szur.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318056 ОГРН 1021607154986 ИНН/КПП 1619000537/161901001

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**«11» ноябрь 2020 г.**

**№15**

Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлегендә биләве коррупция куркынычлары белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12, 13.3 ст. һәм «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 21 июлендәге 925 номерлы Указының 4 пункты,

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советының 2016 елның 22 апрелендәге №29 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлегендә күрсәтелү турында, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» карары,

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 27 декабрендәге 545 номерлы (Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы башкарма комитетының 30.12.2015 № 632; 23.05.2016 № 497, 28.08.2018 № 562; 12.11.2018 № 716, 29.12.2018 № 884; 21.10.2019 № 586; 28.08.2020 №390

карарлары редакциясендә)  карары белән расланган «2015-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы нигезендә,

1.Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлегендә биләве коррупция куркынычлары белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары Исемлеген расларга, кушымта нигезендә.

2. Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге башлыгының 2019 елның 15 ноябре № 15 «Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегендә биләве коррупция куркынычлары белән бәйле булган муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» карары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта дип танырга.

3. Әлеге боерык гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мараков

1 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Иске Җөри авыл җирлеге
башлыгының « 11» декабрь
2020 ел №15 боерыгы белән
расланган

## Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлегендә биләве коррупция куркынычлары белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары Исемлеге

Иске Җөри авыл җирлеге Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары:

1.Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:
Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе
Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе.